# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә, кошчылык, җәнлек асрау, балыкчылык һәм умартачылыкны да кертеп, терлекчелекнең барлык өлкәләрендә нәсел эшен оештыру һәм тормышка ашыруның бердәм принципларын билгели. Закон авыл хуҗалыгы терлекләренең яңа токымнарын, типларын, линияләрен һәм гибридларын чыгару, булганнарын камилләштерү, аларның генофондын саклау, нәсел көтүен яңарту буенча эшчәнлекне дәүләт кызыксындыруына һәм көйләвенә юнәлгән.

### I кисәк. Гомуми нигезләмәләр

**1 статья.** Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше

Авыл хуҗалыгы терлегенең уңай нәсел сыйфатларын саклауга һәм яхшыртуга, аларны продукция җитештерү өчен нәтиҗәле файдалануга, булган малларны камилләштерү һәм яңа токым, тип, линия һәм гибридларын чыгаруга, аларның генофондын саклауга юнәлтелгән гамәлләр комплексын тормышка ашыру нәсел эше дип атала.

**2 статья.** Терлекчелектә нәсел эше буенча законнар

Татарстан Республикасының нәсел эше буенча законнары әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасының аңа туры китереп кабул ителгән башка законнарыннан гыйбарәт.

3 статья. Әлеге Законда файдаланылучы төп төшенчәләр

Нәсел эше предприятиесе - милек рәвешенә карамастан, нәселле маллар яки нәсел продукциясе җитештерүче һәм сатучы, лицензия нигезендә нәсел эше буенча хезмәт күрсәтүче предприятие ул.

Нәсел терлеге - нәселлелек кыйммәте сертификат белән расланган, көтү яңарту һәм нәсел продукциясе алу өчен билгеләнгән, тиешле тәртиптә бәяләнгән, килеп чыгышы төгәл мәгълүм авыл хуҗалыгы терлеге ул.

Нәсел продукциясе - нәселле авыл хуҗалыгы малларыннан алынган һәм сертификатка ия продукция. Нәсел продукциясенә нәселле малларның җенес күзәнәкләре (гаметлар), аларның зиготалары (эмбрионнар) керә.

Терлекнең һәм аның продукциясенең нәселлелек кыйммәте - нәселле малның һәм аның продукциясенең генетик куәте, бу куәтнең хуҗалыкка файдалы токым билгеләренә йогынты ясау дәрәҗәсе.

Бонитировкалау - малларны нәсел һәм продукция бирү сыйфаты буенча комплекслы бәяләү, аларның нәсел һәм хуҗалык максатын билгеләү.

Нәсел терлеге дәүләт кенәгәсе (регистр) - аеруча кыйммәтле маллар һәм көтүләрне теркәү буенча мәгълүматлар җыелмасы ул.

Лицензия - әлеге Закон нигезендә нәсел эше буенча эшчәнлек итү хокукы алу өчен дәүләт нәсел хезмәте биргән махсус рөхсәт кәгазе. Лицензия нәселле малларны үрчетү, нәсел продукциясен җитештерү һәм файдалану өлкәсендә эшләүче хокукый затларга һәм гражданнарга бирелә.

Сертификат (таныклык) - нәсел терлегенең яки аның продукциясенең килеп чыгуы, продуктлылыгы һәм башка сыйфатлары турында мәгълүматларны раслап, дәүләт нәсел хезмәте тарафыннан бирелүче документ.

4 статья. Селекция - нәсел эшчәнлегенә хокук

Селекция - нәсел эшчәнлеге белән шөгыльләнү югары һәм урта махсус уку йортын тәмамлаган, зооинженер һәм зоотехник белгечлеге алган затларга гына рөхсәт ителә.

## II кисәк. Нәсел эшен дәүләт көйләве

5 статья. Татарстан Республикасы дәүләт нәсел хезмәте

Терлекчелектә нәсел эшен оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы дәүләт нәсел хезмәте тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы дәүләт нәсел хезмәтенең бурычлары:

- авыл хуҗалыгында булган малларны камилләштерү, яңа токым, тип, линия һәм гибридларны чыгару;
- нәселле терлекләрнең генетик фондын саклау;
- нәселле терлекләрне нәтиҗәле яңартуны тәэмин итү;
- нәсел көтүен яңарту һәм нәсел продукциясе алу өчен кирәкле нәсел базасы булдыру.

Терлекчелектә нәсел эшенә дәүләт идарәсенең республика һәм җирле органнары дәүләт нәсел хезмәтенең бердәм системасын тәшкил итәләр.

Терлекчелектә нәсел эше буенча дәүләт сәясәтен һәм идарә итү эшчәнлеген авыл хуҗалыгына дәүләт идарәсенең республика органы составына керүче, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан терлекчелектә нәсел эшенә идарә итү буенча махсус вәкаләт бирелгән дәүләт органы гамәлгә ашыра.

Терлекчелектә нәсел эшенә дәүләт идарәсенең республика органы терлекчелектә нәсел эшенә дәүләт идарәсенең җирле органнарын төзи.

Дәүләт нәсел хезмәте структурасы, аның составына керүче оешмалар һәм предприятиеләрнең төрләре Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт нәсел хезмәте предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре, финанс чыганакларына һәм нинди ведомствога буйсынуларына карамастан, республика милкендә булалар.

6 статья. Татарстан Республикасы дәүләт нәсел хезмәте эшчәнлегенең төп юнәлешләре

Татарстан Республикасы дәүләт нәсел хезмәтенә әлеге Закон нигезендә түбәндәгеләр йөкләнә:

- нәсел эше предприятиеләрендә, крестьян (фермер) хуҗалыкларында һәм предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең

ярдәмче хуҗалыкларында селекция - нәсел эшен оештыру һәм тормышка ашыру;

- нәсел хезмәтенә, нәсел эше һәм көтү яңарту предприятиеләре эшчәнлегенә җитәкчелек итү;

- нәселле терлекләрне үрчетү өлкәсендә хокукый затларның һәм гражданнарның эшчәнлеген килештерү;

- нәсел эшен үстерүнең төп принципларын һәм өстен юнәлешләрен эшләү, аның оештыру рәвешләрен камилләштерү;

- авыл хуҗалыгы терлекләрен селекцияләү һәм үрчетү, аларның токым һәм файдалы хуҗалык билгеләрен саклау, камилләштерү буенча программа эшләү һәм аны гамәлгә ашыру;

- нәсел терлекләренең республика генетик (эмбрионнар, сперма продукциясе) фондын булдыру һәм бүлү;

- терлекчелектә нәсел һәм генетик фонд эшен үстерүне дәүләт яклавы буенча чаралар турында тәкъдимнәр эшләү;

- нәсел эшен алып бару буенча күрсәтмә документлар эшләү һәм раслау;

- токым районлаштыруын билгеләү һәм нәсел базасын үстерү, нәселле маллар һәм аларның продукциясе белән тәэмин итү;

- нәсел эше һәм селекция чараларының нәтиҗәлелеген тәэмин итү, нәсел исәп-хисабын, нәтиҗәләрне статистик анализлауны оештыру;

- селекция белгечләренә һәм терлек яңарту технологларына ихтыяҗны билгеләү;

- нәсел терлекчелеге өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен лицензияләр бирү;

- сертификатлар бирү;

- нәсел терлекләренең дәүләт кенәгәләрен (регистрларын) алып баруны һәм бастыруны тормышка ашыру, мәгълүмати тәэмин итү һәм нәсел эше белән бәйле башка гамәлләр кылу;

- терлекчелектә нәсел эше буенча халыкара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру, нәселле маллар һәм аларның продукциясе, нәсел эше өчен махсус җиһазлар, приборлар, материаллар экспортын һәм импортын нигезләү һәм көйләү.

<u>7 статья.</u> Нәсел эше буенча дәүләт күзәтүе

Нәсел эше буенча дәүләт күзәтүе ул - дәүләт нәсел хезмәте

идарәсе органнарының нәсел терлекләренең генетик фондын саклауга, терлекчелектә нәсел эше турында Татарстан Республикасы законнарын бозуны ачу, кисәтү һәм туктату юлы белән нәсел эше предприятиеләрендә, крестьян (фермер) хуҗалыкларында һәм предприятиеләрнең, оешмаларның һәм учреждениеләрнең ярдәмче селекция - нәсел эшен югары дәрәҗәдә тәэмин итүгә юнәлтелгән эшчәнлеге.

Нәсел эше буенча дәүләт күзәтүенә түбәндәгеләр керә:

- терлекчелектә республика селекция-нәсел программаларының нәсел эше предприятиеләре тарафыннан тулы үтәлешен тикшереп тору;

- терлекчелектә селекция - нәсел эшен алып баруда, нәсел терлеген һәм аның продукциясен яңартуда һәм сатуда үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр, кагыйдәләр һәм башка норматив актлар эшләү;

- нәсел исәбен алып баруны һәм нәсел эше буенча хисап бирүне, малларның продуктлылык һәм нәсел сыйфатларын бәяләү буенча норматив актларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

- нәсел терлекчелегендә яңа технологик алымнар, кораллар, җиһазлар, материаллар, биотехнологик ысуллар куллануның тәртибен урнаштыру;

- терлекчелектә нәсел эше буенча законнарны бозуга каршы чаралар күрү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту.

Нәсел эше буенча дәүләт күзәтүе әлеге статьяда күрсәтелгән урындагы затлар тарафыннан башкарыла. Аларның эш тәртибе Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан расланучы Нәсел эше буенча дәүләт күзәтүе турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

Терлекчелектә нәсел эшенә дәүләт идарәсенең республика органы җитәкчесе - бер үк вакытта Татарстан Республикасының нәсел эшенә дәүләт баш инспекторы, ә терлекчелектә нәсел эше буенча дәүләт идарәсенең җирле органы җитәкчесе нәсел эше буенча дәүләт район инспекторы булып тора.

Нәсел эше буенча дәүләт күзәтүен тормышка ашыручы урындагы затларга аларның законлы эшләренә комачаулык итү максатында йогынты ясау законнар нигезендә җаваплылыкка китерә.

8 статья. Нәсел эше буенча дәүләт инспекторлары

Татарстан Республикасының нәсел эше буенча дәүләт баш инспекторы, нәсел эше буенча дәүләт район инспекторлары үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

- терлекчелектә нәсел эше турында законнарның, селекция-нәсел эше һәм терлек яңарту буенча чаралар күрүнең, нәсел эше буенча гамәлдәге кагыйдәләрнең үтәлешен тикшерү максатларында предприятиеләрдә һәм оешмаларда тоткарлыксыз булырга (хезмәт таныклыгын күрсәтеп) һәм тикшерү үткәрергә;

- предприятиеләргә, оешмаларга һәм гражданнарга терлекчелектә селекция - нәсел эше буенча чаралар күрү һәм нәсел эше хакында закон бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирергә, шулай ук әлеге таләпләрнең үтәлешен тикшереп торуны тормышка ашырырга;

- дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына Татарстан Республикасыннан читкә җибәрүчә кыйммәтле нәселле малларны һәм аларның продукциясен чыгаруга чик билгеләү турында, Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында законнарны бозган очракта, кәтү яңарту, нәсел продукциясе җитештерү белән шөгыльләнүче предприятиеләрнең, оешмаларның һәм гражданнарның хуҗалык эшчәнлекләрен туктату хакында тәкъдимнәр кертергә;

- нәсел эшен алып баруда тиешле чаралар күрүгә һәм хокук бозуларны бетергәнчегә кадәр, нәсел продукциясен җитештерүне, сатуны һәм аннан файдалануны туктатып торырга;

- терлекчелектә нәсел эше турында законнарны кабат бозган очракта хокукый затларны һәм гражданнарны лицензиядән мәхрүм итәргә;

- нәсел хисабы алып бару тәртибен бозу ачыкланган очракта нәсел документларына экспертиза үткәрергә;

- нәсел терлекләрен яңартуда нәсел кыйммәте түбән булган терлекләрдән һәм аларның продукциясеннән файдалануны тыярга;

- нәсел терлекчелегендә яңа технологик алымнар, кораллар, җиһазлар, материаллар һәм биотехнологик ысуллар куллануга күчүне тормышка ашырырга;

- терлекчелектә нәсел эше турында законнарны бозуга юл куйган урындагы затларны һәм гражданнарны административ җаваплылыкка тартырга.

9 статья. Житештерүле нәсел хезмәте

Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, күмәк хуҗалыклар, терлекчелек комплекслары, житештерү кооперативлары, акционерлык җәмгыятьләре, агрокомбинатлар, агрофирмалар һәм башкалар үз хисапларына селекция белгечләре һәм көтү яңарту буенча технологлар тота алалар.

Күмәк хуҗалыкларда, агрофирмаларда, агрокомбинатларда, крестьян (фермер) һәм предприятиеләрнең, оешмаларның, гражданнарның ярдәмче шәхси хуҗалыкларында селекция-нәсел эше алып бару һәм малларны яңарту өчен нәсел эше һәм көтү яңарту кооперативлары төзелергә мөмкин.

Селекция белгечләре һәм көтү яңарту буенча технологларның, милек рәвешләренә карамастан, нәсел эше предприятиеләрендәге эшчәнлеге, селекция һәм нәсел эше мәсьәләләре буенча дәүләт нәсел хезмәте тарафыннан тикшереп торыла.

10 статья. Нәсел эше буенча совет

Нәсел эше буенча совет авыл хуҗалыгына дәүләт идарәсенең республика органы тарафыннан югары квалификацияле белгечләрдән һәм галимнәрдән төзелә. Совет үз эшчәнлеген нигезләмәгә таянып гамәлгә ашыра.

Нәсел эше буенча совет селекция, көтү яңарту һәм нәсел эшен оештыру мәсьәләләре буенча эксперт-консультатив орган булып тора. Нәсел эше буенча совет эшенә түбәндәгеләр керә:

- терлекчелектә республика күләмендәге мөһим селекция - нәсел программаларын эшләүдә һәм карауда катнашу, авыл хуҗалыгына дәүләт идарәсенең республика органына аларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кертү;

- терлекнең яңа токымнарын, типларын, линияләрен һәм гибридларын булдыру, булганнарын камилләштерү, көтү яңартуның яңа технологияләрен эшләү буенча республика күләмендәге мөһим фәнни программаларны карау һәм аларны гамәлгә ашыру өчен авыл хуҗалыгына дәүләт идарәсенең республика органына тәкъдимнәр кертү;

- терлекчелектә нәсел эше буенча закон һәм башка хокукый норматив актлар проектларына экспертиза оештыру, аларны башка-

ру механизмы буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- терлекчелектә нәсел эшен дәүләт яклавы буенча чаралар әзерләүдә катнашу;

- генетик фондлары саклanyрга тиешле токымнарны һәм генетик фонд хуҗалыгы статусы бирү мөмкинлеге булган нәсел эше предприятиеләрен ачыклауда катнашу.

11 статья. Нәсел эшен дәүләт яклавы

Нәсел эше предприятиеләрендә селекция-нәсел эшен алып баруда югары дәрәҗәгә ирешү, яңа токымнар, типлар, линияләр һәм гибридлар чыгару һәм булганнарын камилләштерү, генетик фондны саклау һәм нәсел терлекләре яңартуны яхшырту буенча аларның эшчәнлеген кызыксындыру максатында:

- Татарстан Республикасының дәүләт нәсел хезмәте эшчәнлеге авыл хуҗалыгын үстерүгә юнәлтелеп һәм Татарстан Республикасының Республика бюджетына, нәсел терлекчелеген үстерүгә дип аерым язылып, Татарстан Республикасының Республика бюджеты хисабыннан финанслана;

- нәсел терлекләренең генетик фондын саклау, аларның нәсел, продуктлылык һәм башка сыйфатларын камилләштерү Татарстан Республикасының республика бюджетыннан бүлеп бирелгән акчалар хисабына башкарыла;

- терлекләрнең яңа токымнарын, типлар, линияләрен һәм гибридларын чыгаруда, токым сынауда һәм үрчеткечләрне нәсел сыйфаты буенча бәяләүдә, кәтү яңарту буенча яңа технологияләр эшләүдә катнашучы нәсел эше предприятиеләренә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең ярдәмче хуҗалыкларына, шулай ук генетик фонд хуҗалыкларына салым законнары нигезендә ташламалар ясалырга мөмкин;

- селекциядә һәм нәсел эшендә өстенлекле юнәлешкә ия тирән нигезле тикшеренүләр, республика әһәмиятенә ия гамәли тикшеренүләр Татарстан Республикасының Республика бюджетыннан финанслана.

## Ш кисәк. Селекция - нәсел әшен югары дәрәҗәдә тәэмин итү, нәселле терлекләр һәм аларның продукциясенең сыйфатын яхшырту, нәселле терлекләрнең генетик фондын саклау, терлекчелектә селекция казанышларын файдалану буенча таләпләр

### 12 статья. Терлекчелектә нәсел исәбе

Терлекчелектә нәсел исәбе һәм нәсел эше буенча хисап бирү дәүләт нәсел хезмәтенең республика органы билгеләгән рәвешләрдә алып барыла.

Барлык нәселле маллар индивидуаль номерга ия булырга тиешләр. Нәселле малларны номерлау нәсел терлекчелегендә кабул ителгән ысул белән башкарыла.

Кыйммәтле нәсел терлекләре һәм көтүләр, гомумдәүләт милке буларак, катгый рәвештә исәптә тора һәм нәсел терлекләренең дәүләт кенәгәсенә (регистрына) языла. Нәсел терлекләрен дәүләт кенәгәсенә (регистрына) язу нигезләмәгә туры китереп башкарыла.

### 13 статья. Терлекләрне нәсел һәм продуктлылык сыйфатлары буенча бәяләү

Нәсел терлекләрен нәсел һәм продуктлылык сыйфатлары буенча бәяләү өчен барлык нәсел эше предприятиеләрендә ел саен бонитировкалау үткәрелә.

Нәсел терлекләрен бонитировкалау дәүләт нәсел хезмәтенең республика органында билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә үткәрелә.

Нәсел терлекләрен бонитировкалауны селекция белгечләре гамәлгә ашыра.

Нәсел эшендә файдалану өчен сайлап алынган нәсел үрчеткечләр (аталар) токымлылык сыйфаты буенча тикшерелергә һәм бәяләнергә тиешләр.

Продуктлылык һәм токымлылык сыйфаты буенча нәсел үрчеткечләрне (аталарны) тикшерү һәм бәяләү терлекләрнең продуктлылыгы токым стандартында каралган дәрәҗәгә ирешкән хуҗалыкларда һәм фермаларда үткәрелә.

Нәсел үрчеткечләрне (аталарны) тикшерү һәм бәяләү нәтиҗә-

ләреннән чыгып, нәсел эше предприятиеләрендә файдалануга тапшыралар.

14 статья. Нәсел терлекләрен яңарту

Авыл хуҗалыгы терлекләрен ясалма орлыкландыруны һәм эмбрионнарны трансплантацияләүне дәүләт нәсел хезмәтенең республика органы тарафыннан мондый төр эшчәнлеккә бирелгән лицензиясе булган предприятиеләр башкара.

Ясалма орлыкландыру һәм эмбрионнарны трансплантацияләү предприятиесе орлыкларны һәм эмбрионнарны әзерләүне, эшкәртүне, сыйфатын тикшерүне һәм сатуны (бирүне) дәүләт нәсел хезмәтенең республика органында теркәргә тиеш.

Ясалма орлыкландыруны һәм эмбрионнарны трансплантацияләүне көтү яңарту буенча белгеч-технолог башкара.

15 статья. Нәсел терлекләренең генофондын саклау

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан барлык авыл хуҗалыгы нәсел терлекләре милли байлык дип игълан ителәләр, дәүләт яклануында һәм саклануында булалар.

Генофондын саклау таләп ителә торган токымнарны һәм күрсәтелгән токымнарның генофондларын саклау бурычы йөкләнгән нәсел эше предприятиеләрен нәсел эше буенча совет катнашында, дәүләт нәсел хезмәтенең республика органы билгели.

Терлекчелектә нәсел эше буенча дәүләт идарәсенең республика органы җитәкчесе тәкъдиме нигезендә авыл хуҗалыгына дәүләт идарәсенең республика органы селекция максатлары өчен файдалы булган авыл хуҗалыгы терлекләренең аз санлы һәм бетеп баручы токымнарының генофондын саклау буенча дәүләт генофонд предприятиеләре төзи.

Генофонд хуҗалыгы статусына лицензиясе булган нәсел эше предприятиеләре үрчетүне чиста токымлы башкарырга һәм токымның генофондын сакларга тиеш.

Дәүләт нәсел хезмәтенең урындагы затлары нәсел терлекләренең генофондын саклау буенча Татарстан Республикасының терлекчелектә нәсел эше турындагы законнарында каралган махсус гамәлләрне тормышка ашыруны тәэмин итәләр.

Нәсел терлекләрен һәм аларның продукцияләрен Татарстан Республикасында токым районлаштыруын үзгәртүгә китерерлек итеп читтән алу, Татарстан Республикасы ветеринария законнары таләпләрен саклаган килеш, дәүләт нәсел хезмәтенең республика органы биргән лицензияләр буенча гамәлгә ашырыла.

Терлекләрне һәм аларның продукцияләрен читтән алуга рөхсәт түбәндәге шартларда бирелә, әгәр дә:

- терлекнең яисә аның продукциясенең нәсел кыйммәте Татарстан Республикасы нәсел эше предприятиеләрендәге чагыштырылучы терлекләрнең нәсел кыйммәте күрсәткеченнән артык булса;
- мал яисә аның ата-анасы терлекләрнең нәсел сыйфатлары турындагы бәяләмәләре белән нәсел терлекләренең дәүләт кенәгәсенә (регистрына) кертелсә.

Генофондын саклау таләп итеүче терлекне Татарстан Республикасыннан читкә чыгару дәүләт нәсел хезмәтенең республика органы бирә торган лицензия буенча гына рөхсәт ителә.

16 статья. Терлекчелектә селекция казанышы

Терлекчелектә селекция казанышы малларның яңа токымнарыннан гыйбарәт. Токым ана яисә ата җенесле мал (нәсел терлекләре) яки нәсел продукциясе рәвешендә тәкъдим ителергә мөмкин. Саклаучан категориядәге токымга тип, линия, гибрид керә.

Селекция казанышы зерым хокуклар (интелектуаль милек) объекты булып тора һәм аны терлекчелектә файдалану Россия Федерациясенең селекция казанышлары турындагы законнарында каралган тәртиптә генә рөхсәт ителә.

17 статья. Нәсел продукциясен җитештерү һәм сату

Нәсел продукциясе Татарстан Республикасы терлекчелегендә гамәлгә ашырыла торган селекция - нәсел эше программаларында билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

Нәсел продукциясен җитештерүне һәм сатуны гамәлгә ашыручы предприятиеләр, оешмалар һәм гражданнар күрсәтелгән таләпләрнең үтәлешен тәэмин итәргә тиешләр.

18 статья. Нәсел терлекләрен үрчетү өлкәсендә эш итүче хокукый затларның һәм гражданнарның хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы

Нәсел терлекләрен үрчетү өлкәсендә эш итүче хокукый затлар һәм гражданнар түбәндәгеләргә хаклы:

- көтү яңарту өчен селекция-нәсел хезмәтеннән файдаланырга һәм нәсел продукциясенең яраклылыгы хакында бәяләмә алырга;

- сатып алганда терлекнең нәсел яки аның продукциясе кыйммәте турында экспертиза нәтиҗәсен күрсәтүне таләп итәргә;

- нәсел эше буенча эшкуарлык төрләрен мөстәкыйль рәвештә сайлап алырга, дәүләт нәсел хезмәте сертификатына ия булган нәсел терлекләрен һәм аларның продукциясен сатырга һәм сатып алырга;

- нәсел эше буенча ширкәтләргә, җәмгыятьләргә һәм башка берләшмәләргә керергә (берләшергә);

- селекция - нәсел программаларын гамәлгә ашыруда катнашырга;

- әгәр әлеге Законга каршы килмәсә, авыл хуҗалыгы терлекләренең яңа токымнарын, типларын, линияләрен, гибридларын чыгару буенча мөстәкыйль эш алып барырга;

- нәсел терлекләренең һәм аларның продукцияләренең күргәзмә-сатуларында (аукционнарда) һәм смотрларында катнашырга һәм анда үзләренең селекция казанышларын күрсәтергә;

- әлеге Законга каршы килмәүче башка гамәлләрне башкарырга.

Нәсел терлекләрен үрчетү өлкәсендә эш итүче хокукый затлар һәм гражданнар түбәндәгеләрне үтәргә тиешләр:

- нәсел продукциясен җитештерү, саклау, сату һәм тикшереп торуны гамәлгә ашыручы предприятиеләр төзү һәм аларны файдалануга тапшыру өчен нәсел эше буенча дәүләт баш инспекторыннан рөхсәт алырга;

- токымнар районлаштыруын сакларга, дәүләт нәсел хезмәте кабул иткән селекция - нәсел программаларын, терлек токымнарын үрчетү һәм камилләштерү алымнарын үтәргә, терлек генофондын саклауны тәэмин итәргә;

- көтүдә нәсел сыйфаты түбән булган үрчеткечләрдән (аталардан) һәм аларның продукциясеннән файдалануга, табигый кар-

дәш каплатуга, дәүләт нәсел хезмәте сертификаты булмаган терлекләрне нәсел максатлары өчен читтән алып кайтуга юл куймаска;

- гамәлдәге норматив документлар нигезендә зоотехник һәм нәсел исәп-хисабы алып баруны, нәсел турындагы документларны саклауны тәэмин итәргә;

- сатылучы нәсел терлекләренә һәм аларның продукциясенә нәсел кыйммәтен раслаучы кирәкле экспертизалар үткәрергә, бергә теркәп җибәрелә торган документларны рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

- нәсел терлекләрен дөрес үстерүне, туклandыруны, асрауны һәм файдалануны оештырырга;

- кәтү яңарту буенча селекция белгеченә һәм технологка тиешле шартлар тудыруны тәэмин итәргә;

- нәселле терлекләрнең генетик куәтенең продуктлылыгын тулысынча гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хуҗалык һәм технология чараларын башкарырга;

- нәсел эше буенча белгечләрнең селекция-нәсел эшенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлгән күрсәтмәләрен үтәргә.

Нәсел терлекләрен үрчетү елкәсендә эш итүче хокукый затлар һәм гражданнар нәсел терлекләренең генофондын, сәламәтлеген саклау, аларны дөрес туклandыру, асрау һәм файдалану шулай ук югары сыйфатлы нәсел продукциясе җитештерү өчен җаваплы булалар.

19 статья. Нәсел терлекләрен читләштерү һәм нәсел продукциясен кулланудан чыгару

Йогышлы һәм нәселдән килгән авырулар табылган очракта, нәсел терлекләрен читләштерү һәм нәсел продукциясен кулланудан чыгару, Татарстан Республикасының ветеринария законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Предприятиеләр, оешмалар һәм гражданнар нәсел терлекләрен читләштерү яисә нәсел продукциясен кулланудан чыгару нәтиҗәсендә китерелгән зыянны законнар нигезендә кайтарып алырга хокуклы.

Нәселлелек кыйммәте хакында ялган мәгълүмат ачыкланганда, нәсел продукциясе Татарстан Республикасының нәсел эше буенча

баш дәүләт инспекторы карары нигезендә кулланудан чыгарылырга мөмкин. Бу очракта нәсел продукциясен кулланудан чыгару нәтиҗәсендә предприятиеләргә, оешмаларга һәм гражданнарга килгән зыян нәсел продукциясен нәселлелек кыйммәте хакында ялган мәгълүмат белән саткан предприятиедән хөкем тәртибендә кайтарып алына.

Нәселлелек кыйммәте хакында ялган мәгълүматлы нәсел терлеген читләштерүгә юл куелмый, әмма Татарстан Республикасының нәсел эше буенча баш дәүләт инспекторы карары нигезендә аны нәсел максатларында файдалану тыела. Аның нәсел сыйфатларын раслаучы сертификат гамәлгә яраксыз булып санала. Бу очракта сыйфат сертификатын юкка чыгару нәтиҗәсендә предприятиеләргә, оешмаларга һәм гражданнарга китерелгән зыян нәсел терлеген нәселлелек кыйммәте хакында ялган мәгълүмат белән саткан предприятиедән хөкем тәртибендә кайтарып алына.

## IV бүлек. Нәсел эшен матди-техник һәм фәнни яктан тәэмин итү

### 20 статья. Нәсел хезмәте күрсәтүне финанслау

Нәсел эше предприятиеләрен һәм дәүләт нәсел хезмәте органнарын финанслауның чыганаклары түбәндәгеләр: Татарстан Республикасының нәселле терлекчелек үсешенә юнәлдерелгән Республика бюджеты акчалары, нәсел терлекләрен һәм аларның продукциясен сатудан керген, шулай ук килешүләр буенча башкарылган эшләрдән кергән акчалар.

### 21 статья. Нәсел хезмәтен һәм нәсел эше предприятиеләрен матди-техник яктан тәэмин итү

Нәсел хезмәте учреждениеләрен, нәсел эше предприятиеләрен, көтү яңарту буенча күмәк хуҗалыкларны, башка предприятиеләрне һәм оешмаларны, эшкуарлык белән шөгыльләнүче белгечләрне нәсел эше буенча матди-техник чаралар белән тәэмин итү зооветеринар юнәлештәге дәүләт тәэминат оешмаларына йөкләнә. Тәэмин итү дәүләт нәсел хезмәте органнарының гаризасы буенча гамәлгә

ашырыла.

22 статья. Нәсел эшен фәнни яктан тәэмин итү

Терлекчелектә нәсел эшен фәнни яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасының фәнни, югары уку һәм фәнни-житештерү учреждениеләре башкаралар.

Нәсел эше буенча фәнни тикшеренүлер дәүләт нәсел хезмәтенә авыл хуҗалыгына идарә итү органнары һәм нәсел эше предприятиеләре гаризасы буенча килешүләр нигезендә үткәрелә һәм алар тарафыннан финанслана.

Фәнни учреждениеләр коллективлары дәүләт нәсел хезмәте һәм кызыксынучы ведомстволар белән бергә түбәндәгеләрне эшлиләр:

- булган терлекләрне камилләштерү һәм яңа токымнар, типлар, линияләр һәм гибридлар чыгару буенча селекция-генетика программаларын;

- селекция гамәленең, көтү яңартуның, малларның нәсел һәм продукция сыйфатларын яхшыртуның нәтиҗәлелеген арттыру алымнарын, юлларын һәм ысулларын;

- нәсел хисабын алып бару ысулларын һәм авыл хуҗалыгы терлекләрен бәяләү буенча алымнарны;

- нәсел эше өчен тикшерү-үлчәү приборларын һәм башка техник чараларны;

- нәсел терлекчелегендә мәгълүмат системаларын.

## V бүлек. Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында законнарны бозган өчен җаваплылык

23 статья. Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында законнарны бозган өчен җаваплылык

Нәсел эше предприятиеләренең урындагы затлары һәм гражданнар түбәндәге хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тартылалар:

- дәүләт нәсел хезмәте сертификаты булмаган терлекләрне һәм аларның продукциясен сату (бирү) һәм нәсел максатларында

файдалану;

- нәсел терлекләрен (аларның продукциясен) сатканда, шулай ук аларның продуктлылыгын, нәсел һәм башка сыйфатларын бәяләгәндә күрсәтмәләрне һәм норматив актларны үтәмәү;

- нәсел исәп-хисабын алып бару кагыйдәләрен бозу;

- терлекнең һәм аның продукциясенең нәсел кыйммәте турында ялган мәгълүмат бирү;

- көтү яңартуда тикшерелмәгән технологияләр куллану;

- көтү яңартуда нәсел кыйммәте түбән булган үрчеткечләрне (аталарны) һәм аларның продукциясен файдалану;

- сатыла торган терлекләрнең һәм аларның продукциясенең нәсел кыйммәте дәрәҗәсен экспертиза үткәрүдән баш тарту;

- терлекчелектә республиканың расланган селекция - нәсел программаларын үтәмәү;

- махсус зоотехния белеме һәм дәүләт нәсел хезмәте лицензиясе булмыйча торып, селекция-нәсел эшчәнлеге белән шөгыльләнү;

- нәсел эше буенча дәүләт инспекторларының законлы эшчәнлегенә комачаулау нияте белән йогынты ясау;

- терлекчелектә нәсел эше турындагы законнарны үтәмәү;

- дәүләт нәсел эшен күзәтү органнары белән килештермичә торып, нәсел продукциясен җитештерү һәм саклау өчен объектлар планлаштыру һәм төзү.

Штраф салу һәм башка җаваплылыкка тарту гаепләләрне зыян кайтарудан азат итми.

<u>24 статья.</u> Нәсел эше буенча дәүләт инспекторлары куллана торган административ җаваплылык чаралары

Административ штрафлар түбәндәгечә салына:

Татарстан Республикасының нәсел эше буенча дәүләт баш инспекторы тарафыннан урындагы затларга 9 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр һәм гражданнарга 3 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр; нәсел эше буенча район дәүләт инспекторы тарафыннан урындагы затларга - 6 һәм гражданнарга 2 минималь хезмәт хакы күләменә кадәр.

Әлеге Закон нигезендә нәсел эшен дәүләт күзәтүе органнары штраф салудан кергән акчалар түбәндәге тәртиптә бүленә: 50 проценты - җирле бюджетка һәм 50 проценты тиешле дәүләт нә-

сел хезмәте карамагына керә һәм нәсел эше үсешенә тотыла.

Терлекчелектә нәсел эше турында законнарны бозу кабатланганда, хокукый затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасының нәсел эше буенча баш дәүләт инспекторы карары нигезендә лицензиядән мәхрүм ителергә мөмкин.

Хокукый затларны һәм гражданнарны лицензияләреннән мәхрүм итү каралган хокук бозулар исемлеге Нәсел терлекчелеге өлкәсендәге эшчәнлекне лицензияләү турындагы нигезләмә тарафыннан билгеләнә.

25 статья. Административ җаваплылык чарасын куллану турындагы карарга шикаять белдерү

Административ җаваплылык чараларын куллану турында нәсел эше буенча дәүләт инспекциясе карарына шикаять белдерү законнарда каралган тәртиптә башкарыла.

## VI бүлек. **Халыкара шартнамәләр**

26 статья. Халыкара шартнамәләр

Әгәр терлекчелек, терлекчелектә селекция, нәсел терлекләрен һәм аларның продукцияләрен читкә чыгару һәм читтән кертү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы катнашындагы халыкара шартнамәдә, әлеге Законнан үзгә кагыйдәләр билгеләнгән булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 28 марты

№482